СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09.2019 с. Татарское Бурнашево 65-298

**Бурнаш авыл җирлеге территориясендә**
**үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Бурнаш авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Бурнаш авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 11.09.2009 ел, № 64-294 карары, Бурнаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 11.09.2009 ел, № 15 карары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Бурнаш авыл җирлеге**
**карар чыгарды:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Бурнаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Бурнаш авыл җирлегендә вак таш җәю һәм вак таш җәелгән юлларны төзекләндерү

**ӘЙЕ** **ЮК»**

3. Әлеге карарны « Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль

районының рәсми сайтында, Бурнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Бурнаш авыл җирлеге**
**Башлыгы** **С.В.Бурукин**